# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану һәм транспортны саклау, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында

/1993 елның 13 июлендәге Татарстан Республикасы Законы тарафыннан кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән/

Әлеге Закон юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, анда катнашучыларның һәм транспорт чараларыннан файдалануда җаваплы урындагы затларның җаваплылыгын арттыруга, юл хәрәкәтен оештыру буенча автомобиль юлларын һәм техник чараларны тотуга юнәлтелгән.

1 статья. Юл хәрәкәте яисә транспорт чараларыннан файдалану кагыйдәләрен матди зыян китерерлек итеп бозган өчен, -

бер минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Тормоз системасы, руль идарәсе яисә тарту-тагылма җайланмасы /автопоезд составында/ төзек булмаган транспорт чараларын йөрткән өчен, -

0,3 тән алып 0,5 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Дәүләт номер тамгасы, шулай ук куелма номер тамгалары булмаган, әмма теркәлгән транспорт чараларын йөртүчеләргә, -

ике минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Ябылган яисә ябылып килүче шлагбаумлы, светофорның тыю уты янганда яисә аркылы чыгу урынында кизү торучы тыю сигналы күрсәткәндә тимер юл аркылы чыккан өчен, -

бердән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә күрсәтелгән документларны үзе белән алмаган транспорт йөртүчеләрнең транспорт чараларын йөртүләре өчен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән яисә дәүләт техник тикшерүе узмаган, яки булган төзексезлекләре аркасында юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә транспорт чараларыннан файдалану тыелган очракта /моңа әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән төзексезлекләр керми/ мондый транспорт чараларын йөртүләре өчен,-

0,1 дән алып 0,3 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләрнең билгеләнгән хәрәкәт тизлеген 10нан алып 30 км/сәг.кә кадәр арттырулары өчен, юл тамгалары һәм транспорт йөри торган урыннардагы билгеләрнең таләпләрен үтәмәүләре өчен( моңа әлеге статьяның тугызынчы өлешендә күрсәтелгән очраклар керми) җәмәгать транспорты тукталышлары турысында транспорт чараларын йөртү, җәяүлеләр урамнарны аркылы чыгу урыннары, транспорт чараларын транспорт йөри торган урыннарга урнаштыру, тукталышлар, туктап тору урыннары, буксирга алу, йөк ташу, тышкы яктылык җайланмаларыннан, тавыш сигналларыннан, иминлек каешларыннан яисә мотошлемнардан файдалану кагыйдәләрен бозулары өчен,-

0,3 минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен,-

гражданнарга - 0,1 дән алып 0,3 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, урындагы затларга 0,5 тән алып бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләрнең стандарт булмаган, укымаслык яисә Юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләрен бозарлык итеп урнаштырылган

номер тамгалы транспорт чараларын йөртүләре өчен,-

0,1 дән алып 0,3 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр тарафыннан хәрәкәтнең билгеләнгән тизлеген 30 км/сәг. тән дә арттырган, светофорның һәм юл хәрәкәтен җайга салучының тыю сигналына да карамыйча, хәрәкәтне дәвам иткән,"Керү тыела", "Хәрәкәт тыела", "Куркыныч" дигән юл тамгалары таләпләрен үтәмәгән,капма-каршы юнәлешләрнең транспорт агымнарын бүлүче тоташ сызык билгеләренең теге ягына чыккан, тимер юл аркылы чыгу урыннарындагы хәрәкәт кагыйдәләрен бозган( моңа әлеге статьяның дүртенче өлешендә күрсәтелгәннәр керми) башкаларны узып китү, маневр ясау, кешеләр йөртү кагыйдәләрен бозган, транспорт чараларын йөртүдә өстенлек хокукына ия булган транспорт йөртүчеләргә һәм өстен хокукларга ия булган җәяүлеләргә юл бирмәгән өчен,-

0,5 минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Юл хәрәкәтенең әлеге Законның статьяларында караламаган башка кагыйдәләрен үтәмәгән өчен, -

кисәтү ясала.

Транспорт йөртүчегә административ җәза биргәндә бер үк вакытта тәртип бозуына түбәндәге , балларда бәя куела:

1 өлеш - 5 балл

3,4 өлешләр - 4 балл

2,5,9 өлешләр - 3 балл

6,7,8 өлешләр - 2 балл

10 өлеш - 1 балл.

Транспорт йөртүчеләр Юл хәрәкәте кагыйдәләрен даими рәвештә бозган өчен, ягъни беренче статьяда күрсәтелгән тәртип бозуларны ел дәвамында берничә мәртәбә кабатлаган өчен, суммада ул унбиш һәм аннан да артыграк балларда күрсәтелә, -

икедән алып өч минималь хезмәт хакына кадәр штраф салына яисә транспорт чараларын йөртү хокукыннан өч айдан алып алты айга кадәр мәхрүм ителә.

2 статья. Транспорт чараларын йөртүгә хокуклары булмаган затларның транспорт чараларын йөртүләре өчен, шулай ук транспорт чараларын йөртү хокукы булмаган затка транспорт чарасын йөртүне тапшырган өчен, -

бер минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән затлар транспорт чараларын йөрткән өчен, -

бердән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

3 статья. Автотранспортны махсус яктылык һәм тавыш сигналлары белән тәэмин итүнең билгеләнгән тәртипләрен бозган өчен, -

транспорт чараларын йөртүчеләргә - бер минималь хезмәт хакы күләмендә, урындагы затларга ике минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

4 статья. Әлеге Законның беренче статьясындагы 4,6,9 өлешләрендә күрсәтелгән, авария вәзгыяте китереп чыгарган, ягъни хәрәкәттә катнашучыларны тизлекләрен, хәрәкәт юнәлешен кинәт үзгәртергә, яисә үз иминлеген яки башка гражданнар иминлеген тәэмин итәрлек башка чаралар кулланырга мәҗбүр иткән гамәлләре өчен, -

икедән алып өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә өч айдан алып алты айга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

5 статья. Мотоцикл һәм башка транспорт чараларын йөртүчеләр шәһәрләрдәге һәм башка торак пунктларындагы юл хәрәкәтендә кыенлыклар китереп чыгаручы яисә хәрәкәт иминлегенә янаучы күмәкләшеп йөрүдә катнашулары өчен, -

бер ярым минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына яисә алар транспорт чараларын йөртү хокукыннан алты айга кадәр мәхрүм ителә.

6 статья. Транспорт чараларын исерек килеш йөрткән өчен, -

транспорт йөртүчеләр бер елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә яисә аларга дүрттән алып алты минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Бер ел эчендә кабатланган шундый ук гамәлләр өчен, -

өч елдан алып биш елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә яисә биштән алып җиде минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Транспорт чараларын йөртергә хокукы булмаган исерек затларга транспорт чараларын йөртүләре өчен, -

сигез минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Бер ел эчендә кабатланган шундый ук гамәлләр өчен, -

ун минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

8 статья. Исерек затка транспорт чарасын йөртүне тапшырган өчен, -

дүрттән алып алты минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә бер елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

Транспорт чараларын йөртергә хокукы булмаган һәм исерек затларга транспорт чараларын йөртүне тапшырган өчен, -

сигез минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына яисә бер елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

9 статья. Транспорт чараларын йөртүчеләрнең исереклекне билгеләнгән тәртиптә таныклаудан баш тартулары өчен, -

биштән алып сигез минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә бер елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

10 статья. Милиция хезмәткәренең транспорт чарасын туктату хакында кул, таяк ишарәсе белән, сызгы яисә тавыш көчәйткеч җайланмасы ярдәмендә сигнал бирү рәвешендәге законлы таләпләрен транспорт чараларын йөртүчеләрнең үтәмәүләре өчен,-

бердән алып биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә бер елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

Милиция хезмәткәренең юл-транспорт вакыйгасыннан килгән зыянны бетергәндә бушлай ярдәм күрсәтү турындагы таләпләрен транспорт чараларын һәм юл механизмнарын йөртүчеләрнең үтәмәүләре өчен,-

бер минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

11 статья. Юл хәрәкәте яисә транспорт чараларыннан файдалану кагыйдәләрен җиңелчә тән җәрәхәтләре китереп чыгарырлык итеп бозган өчен,-

бердән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә алты айдан алып бер елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

12 статья. Юл-транспорт вакыйгасы булган урында транспорт чараларын йөртүчеләрнең, вакыйгада катнашучы булып та, билгеләнгән кагыйдәләрне бозып, транспорт чараларын ташлап китүләре өчен,-

дүрттән алып алты минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә бер елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

13 статья. Җәяүлеләрнең Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозулары өчен,-

кисәтү ясала яисә 0,1 минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Мопед, велосипед йөртүчеләрнең Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозулары өчен, шулай ук юл хәрәкәте барышында турыдан-туры катнашучы йөкчеләрнең, пассажирларның яисә башка затларның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозулары өчен,-

0,1 дән алып 0,2 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә күрсәтелгән затларның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен исерек килеш бозулары өчен,-

0,1 дән алып 0,5 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә күрсәтелгән затларның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен матди зыян китерерлек итеп бозулары өчен,-

0,1 дән алып 0,5 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә күрсәтелгән затларның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен җиңелчә тән җәрәхәтләре китереп чыгарырлык итеп бозулары өчен,-

0,2 дән алып бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

<u>14 статья.</u> Төзексезлекләре аркасында файдаланырга тиешле булмаган яисә җайланмалары рөхсәтсез үзгәртелгән, яки билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән, яисә дәүләт техник тикшерүе узмаган транспорт чараларын юлга чыгарган өчен,-

транспорт чараларының техник торышы һәм транспорт чараларыннан файдалану өчен җаваплы урындагы затларга 0,5 тән алып бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Исерек килеп транспорт йөртүчеләргә яисә транспорт чараларын йөртүгә хокукы булмаган затларга транспорт чараларын йөртүне рөхсәт иткән өчен,-

транспорт чараларының техник торышы һәм алардан файдалану өчен җаваплы урындагы затларга бердән алып өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чаралары йөртүгә хокукы булмаган затка һәм исереккә транспорт чаралары йөртергә рөхсәт биргән өчен,-

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына биштән алып сигез минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

I5 статья. Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның транспортыннан, машиналарыннан яки механизмнарыннан башбаштакланып файдаланган өчен,-

транспорт чараларын йөртүчеләргә бердән алып өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә ул алты айдан бер елга кадәр транспорт йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

I6 статья. Юлларны, тимер юлларны аркылы чыгу урыннарын, юл хәрәкәтен җайга салуның башка техник чараларын бозган өчен яисә ДАИ оешмалары рөхсәтеннән башка үзбелдекләнеп юл тамгалары билгеләгән өчен, шулай ук юл хәрәкәтендә тоткарлыклар китереп чыгарган өчен, шул исәптән, юл өслеген пычратып, тоткарлыклар китереп чыгарган өчен дә,-

бердән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә алты айга кадәр транспорт йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

Юл өслегендә һәм юл кырыенда рөхсәтсез /ордерсыз/ җир эшләре башкарган өчен, җир эшләрен башкаруның вакытларын үтәмәгән, җир эшләрен башкаруның кагыйдәләрен бозган, эшләрне башкарганнан соң асфальт өслеген, газоннарны һәм юл кырыйларын төзәтмәгән яисә сыйфатсыз төзәткән өчен,-

урындагы затларга - бердән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга бер минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Рөхсәт нигезендә генә транспортта башкарыла торган эшчәнлекне махсус рөхсәт /лицензия/ булмый торып башкарган өчен,-

гражданнарга һәм урындагы затларга икедән алып биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Махсус рөхсәттә /лицензиядә/ каралган шартларны бозган өчен,-

гражданнарга һәм урындагы затларга 0,5 тән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

17 статья. Юлларны, тимер юлларны аркылы чыгу урыннарын, юл хәрәкәтен көйләүче башка техник чараларны тоту кагыйдәләрен бозган өчен, шулай ук юл астыннан үтә торган җир асты коммуникацияләрен карау коеларын юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итәрлек хәлдә тотмаган өчен яисә юл хәрәкәте иминлегенә янаучы [illegible] хәлдә булган аерым юл кисәкләрендә йөрүне вакытында тыймаган яки чикләмәгән өчен, юл-урам челтәрен төзәткән вакытта хәрәкәт иминлеген тәэмин итүче тиешле юл тамгаларын файдаланмаган өчен,-

юллар, тимер юлларны аркылы чыгу урыннары һәм башка юл җайланмалары һәм коммуникация хуҗалыгы өчен җавап бирүче урындагы затларга икедән алып биш минималь хезмәт хакы күләмен[illegible] штраф салына.

18 статья. Яктылык үткәрүчәнлеге билгеләнгән кагыйдәләргә туры килмәгән караңгы пыялалы яисә тонлы көзге ысулы белән капланган пыялалы транспорттан файдаланган транспорт йөртүчеләргә,-

ике минималь хезмәт хакы күләмендә кадәр штраф салына.

19 статья. Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның автомобильләрен, мотоциклларын, тракторларын һәм аларга тагылмаларны эштән соң [illegible] куярга билгеләнгән махсус урыннарда сакламаган өчен,-

транспорт чаралары йөртүчеләргә - бердән алып ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, транспорт чараларыннан файдалану өчен җаваплы затларга икедән алып дүрт минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

20 статья. Куркыныч, зур күләмле һәм авыр йөкләрне Дәүләт автоинспекциясе һәм шуның белән кызыксынучы ведомстволар рөхсәтеннән башка йөрткән өчен,-

транспорт чаралары йөртүчеләргә - бер минималь хезмәт хакы күләмендә, ә йөкләр ташу өчен җаваплы урындагы затларга ике минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

Куркыныч, зур күләмле һәм авыр йөкләрне йөртү кагыйдәләрен бозган өчен, бу элемтә челтәрен өзүгә китерсә, транспортка, юлларга, йөкләргә, юл корылмаларына һәм башка корылмаларга яисә бүтән төрле мөлкәткә зыян китерсә,-

транспорт чаралары йөртүчеләргә - өч минималь хезмәт хакы күләмендә, ә йөкләрне ташу өчен җаваплы урындагы затларга биш минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салына.

21 статья. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүче кагыйдәләрне, нормативларны һәм стандартларны бозуны кисәтү хакында Дәүләт автомобиль инспекциясе күрсәтмәләрен белә торып үтәмәгән өчен,-

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүче урындагы затларга бердән алып өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

22 статья. Административ хокук бозу турындагы беркетмәне гамәлдәге законнар нигезендә Дәүләт автомобиль инспекциясе яисә юлпатруле хезмәте инспекторлары, эчке эшләр органнарының башка вәкаләтле урындагы затлары, хәрби автомобиль инспекциясе инспекторлары, шулай ук җәмәгать инспекторлары һәм дружиначылары төзи һәм биш көн эчендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәка-

лэтле органга /урындагы затка/ җибәрә.

Беркетмәдә барлык реквизитлар тутырыла. Аңа тәртип бозучының аңлатмасы һәм эшне хәл итү өчен кирәкле башка мәгълүматлар беркетелә. Беркетмәгә аны төзегән зат тарафыннан һәм административ хокук бозучы зат тарафыннан имза салына; шаһитлар һәм зыян күрүчеләр булганда, беркетмәгә алар тарафыннан да имза салынырга мөмкин.

Әгәр тәртип бозган зат үзенең тәртип бозуыннан һәм әлеге Законның 1 статьясындагы икенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы һәм унынчы өлешләрендә, 13 статьясындагы беренче, икенче, өченче һәм дүртенче өлешләрендә каралган штраф рәвешендәге аңа салынган административ җәза чараларыннан баш тартмаса беркетмә төзелми. Бу очракларда салына торган штраф вакыйга булган урында гамәлдәге законнар нигезендә алына. Тәртип бозучыга штраф салыну турында билгеләнгән үрнәктәге квитанция бирелә, ул төгәл финанс хисабы өчен документ булып тора. Тәртип бозучы болар белән килешмәгән очракта, беркетмә төзелә һәм бу эш әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә карала.

Транспорт йөртүчегә административ җәза билгеләгәндә бер үк вакытта транспорт йөртүченең транспорт йөртү таныклыгындагы талонына тамга салына.

23 статья. Әлеге Законның 22 статьясындагы өченче өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, әлеге Законда каралган тәртип бозулар турындагы эшләр республиканың, шәһәрләрнең, районнарның баш дәүләт автомобиль инспекторлары яисә аларның урынбасарлары тарафыннан карала. Эчке эшләр бүлегендә Дәүләт автомобиль инспекциясе бүлекчәсе /бүлеге/ булмаганда, күрсәтелгән эшләр эчке эшләр бүлеге башлыгы яисә җәмәгать иминлеге хезмәтенең башлыгы тарафыннан карала. Әлеге Законда күрсәтелгән хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкка җәлеп итү турында урындагы затлар тарафыннан дәлилле карар

чыгарыла һәм бер үк вакытта әлеге хокук бозуны кылган затның транспорт йөртү таныклыгындагы талонына тамга салына.

Милиция хезмәткәрләренә әлеге Законның 13 статьясындагы беренче, икенче, өченче һәм дүртенче өлешләрендә күрсәтелгән тәртип бозулар өчен административ җәза билгеләү хокукы бирелә.

24 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне, эчке эшләр органнарының урындагы затлары карарларына шикаятьләрне һәм ризасызлык белдерүләрне карау тәртибе гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

25 статья. Алты айга һәм аннан да күбрәккә транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән затка, юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча белемен һәм транспорт йөртү осталыгын тикшергәннән соң, транспорт йөртү таныклыгы кире кайтарыла.

26 статья. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозганда беркетмә төзелсә, эш буенча карар кабул ителгәнче, транспорт йөртүченең транспорт йөртү таныклыгы алына һәм транспорт чараларын йөртү өчен вакытлыча рөхсәт бирелә, бу турыда беркетмәгә языла.

27 статья. Исерек килеш транспорт чараларын йөрткән өчен яисә Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә күрсәтелгән тиешле документлары булмаганда, эчке эшләр органнары транспортны махсус саклана торган урыннарда /саклаган өчен түләтеп/ тоткарларга хаклы. Тиешле документларны күрсәткәннән соң, вакытлыча тоткарланган транспорт чарасы, аның транспорт йөртү таныклыгы булса, - иясенә, ә таныклыгы булмаганда транспорт йөртүгә кирәкле тиешле документлары булган ышанычлы затка кайтарыла. Кирәкле документлар күрсәтелмәгән очракта, эш каралганчы һәм билгеләнгән җәза үтәлгәнче, транспорт чарасы тоткарлана.

Транспорт чарасын һәм йөкләрне тоткарлау аерым актта күрсәтелә, ә административ хокук бозу турындагы беркетмәдә тиешенчә язып куела.

Вакытлыча тоткарланган транспорт чараларын саклау, аларны кире кайтару һәм, вакыты җитеп тә, соратып алынмаган очракта, транспорттан файдалану тәртибен, аны саклаган өчен түләүхакын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

Транспорт чарасы законсыз тоткарланган очракта гына, транспортны тоткарлаган урындагы зат транспорт иясенә китерелгән зыян өчен җаваплы була.

Транспорт чаралары йөртүчеләрнең яисә башка затларның исерек булулары турында тиешле дәлилләр булганда, исереклекләрен таныклау өчен, алар билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә тиешләр.

Күрсәтелгән затларны исереклекләрен таныклау өчен тикшерүгә җибәрү һәм тикшерү Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

28 статья. Транспорт йөртүчене транспорт чарасын йөртү хокукыннан мәхрүм итү турында карар чыгарылган көннән ул транспорт йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән дип санала.

Транспорт чаралары йөртү хокукыннан мәхрүм ителүче транспорт йөртү таныклыгын тапшырудан баш тартса, аны транспорт чараларын йөртүдән мәхрүм ителү чоры таныклыкны тартып алган мизгелдән исәпләнелә башлый, әмма транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм итү турында карар кабул итүче урындагы зат билгеләгән вакытыннан да соңрак түгел.

29 статья. Кылган административ хокук бозу мөһим әһәмияткә ия булмаса һәм бу беркетмәдә күрсәтелсә, хокук рәвешенә һәм хокук бозучының шәхесенә карап, әлеге эшне каравга вәкаләтле урындагы зат, дәлилләнгән бәяләмә чыгарып, кисәтү рәвешендәге административ чара да кулланырга мөмкин.

30 статья. Транспорт йөртү таныклыгына талонын яисә транспорт йөртү өчен бирелгән вакытлыча рөхсәтен югалтканда, Юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча белемен һәм транспорт йөртү осталыгын тикшергәннән соң транспорт йөртү таныклыгы транспорт иясенә кире кайтарыла.

Транспорт йөртү таныклыгының талоны транспорт йөртүгә хокук бирми.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 17 мае
1864-XII